**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений**
**в Закон Республики Татарстан «О недрах»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
20 февраля 2018 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 25 декабря 1992 года № 1722-XII «О недрах» (в редакции Закона Республики Татарстан от 6 декабря 1999 года № 2486) (Ведомости Верховного Совета Татарстана, 1992, № 11 – 12; Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2000, № 2 (2); 2001, № 12; 2004, № 7 (I часть); 2005, № 4 (I часть); 2008, № 3; 2009, № 9 – 10; 2012, № 1, № 7 (I часть), № 12 (II часть); 2014, № 1 – 2, № 4, № 5, № 12 (II часть); 2015, № 7 (I часть); 2016, № 3; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 44 (часть I) следующие изменения:

1) статью 13 дополнить частью четвертой следующего содержания:

«Пользователями недр на участках недр местного значения, которые содержат общераспространенные полезные ископаемые и включены в перечень участков недр местного значения, утвержденный органом управления государственным фондом недр, и которые предоставляются в пользование в соответствии с абзацем семнадцатым статьи 16 настоящего Закона, могут быть юридические лица, с которыми заключены гражданско-правовые договоры на выполнение работ по строительству, реконструкции, капитальному ремонту, ремонту и содержанию автомобильных дорог общего пользования в соответствии с Федеральным законом от 5 апреля 2013 года № 44-ФЗ «О контрактной системе в сфере закупок товаров, работ, услуг для обеспечения государственных и муниципальных нужд» или Федеральным законом от 18 июля 2011 года № 223-ФЗ «О закупках товаров, работ, услуг отдельными видами юридических лиц».»;

2) в статье 15:

а) часть вторую дополнить абзацем следующего содержания:

«на срок выполнения работ по строительству, реконструкции, капитальному ремонту, ремонту и содержанию автомобильных дорог общего пользования – для разведки и добычи общераспространенных полезных ископаемых на участках недр местного значения, которые содержат общераспространенные полезные ископаемые и включены в перечень участков недр местного значения, утвержденный органом управления государственным фондом недр, и которые предоставляются в пользование в соответствии с абзацем семнадцатым статьи 16 настоящего Закона.»;

б) часть пятую изложить в следующей редакции:

«Срок пользования участком недр продлевается по инициативе пользователя недр в случае необходимости завершения поисков и оценки или разработки месторождения полезных ископаемых либо выполнения ликвидационных мероприятий при условии отсутствия нарушений условий лицензии данным пользователем недр.»;

3) статью 16 дополнить абзацем следующего содержания:

«о предоставлении без проведения конкурса или аукциона права пользования участком недр местного значения, содержащим общераспространенные полезные ископаемые и включенным в перечень участков недр местного значения, утвержденный органом управления государственным фондом недр, для разведки и добычи общераспространенных полезных ископаемых, необходимых для целей выполнения работ по строительству, реконструкции, капитальному ремонту, ремонту и содержанию автомобильных дорог общего пользования, осуществляемых на основании гражданско-правовых договоров на выполнение указанных работ, заключенных в соответствии с Федеральным законом от 5 апреля 2013 года № 44-ФЗ «О контрактной системе в сфере закупок товаров, работ, услуг для обеспечения государственных и муниципальных нужд» или Федеральным законом от 18 июля 2011 года № 223-ФЗ «О закупках товаров, работ, услуг отдельными видами юридических лиц».»;

4) в части первой статьи 21 слова «федеральным законом» заменить словом «законодательством»;

5) в статье $35^1$:

а) в части первой слово «шестым» заменить словом «седьмым»;

б) в части второй:

абзац первый после слов «без проведения» дополнить словами «конкурса или»;

дополнить абзацем следующего содержания:

«разведка и добыча общераспространенных полезных ископаемых, необходимых для целей выполнения работ по строительству, реконструкции, капитальному ремонту, ремонту и содержанию автомобильных дорог общего пользования, осуществляемых на основании гражданско-правовых договоров на выполнение указанных работ, заключенных в соответствии с Федеральным законом от 5 апреля 2013 года № 44-ФЗ «О контрактной системе в сфере закупок товаров,

работ, услуг для обеспечения государственных и муниципальных нужд» или Федеральным законом от 18 июля 2011 года № 223-ФЗ «О закупках товаров, работ, услуг отдельными видами юридических лиц».»;

6) в статье $35^{3}$:

а) наименование после слов «без проведения» дополнить словами «конкурса или»;

б) в части второй цифры «$35^{8}$» заменить цифрами «$35^{8.1}$»;

7) дополнить статьей $35^{8.1}$ следующего содержания:

**«Статья $35^{8.1}$. Документы, необходимые для предоставления права пользования участком недр местного значения для разведки и добычи общераспространенных полезных ископаемых, необходимых для целей выполнения работ по строительству, реконструкции, капитальному ремонту, ремонту и содержанию автомобильных дорог общего пользования**

Для предоставления права пользования участком недр местного значения для разведки и добычи общераспространенных полезных ископаемых, необходимых для целей выполнения работ по строительству, реконструкции, капитальному ремонту, ремонту и содержанию автомобильных дорог общего пользования, осуществляемых на основании гражданско-правовых договоров на выполнение указанных работ, заключенных в соответствии с Федеральным законом от 5 апреля 2013 года № 44-ФЗ «О контрактной системе в сфере закупок товаров, работ, услуг для обеспечения государственных и муниципальных нужд» или Федеральным законом от 18 июля 2011 года № 223-ФЗ «О закупках товаров, работ, услуг отдельными видами юридических лиц», необходимы документы, предусмотренные частью первой статьи $35^{2}$ настоящего Закона, а также:

документ об уплате государственной пошлины за предоставление лицензии на пользование недрами;

копия топографического плана участка недр местного значения, предоставляемого в пользование (в трех экземплярах);

пояснительная записка, отражающая состояние участка недр местного значения, предоставляемого в пользование, на момент подачи заявки и содержащая сведения о планируемых сроках начала работ и предлагаемых мероприятиях по охране недр и окружающей среды;

копия протокола утверждения запасов общераспространенных полезных ископаемых на участке недр местного значения, предоставляемом в пользование;

копия договора на выполнение работ по строительству, реконструкции, капитальному ремонту, ремонту, содержанию автомобильных дорог общего пользования, заключенного в соответствии с Федеральным законом от 5 апреля 2013 года № 44-ФЗ «О контрактной системе в сфере закупок товаров, работ, услуг для обеспечения государственных и муниципальных нужд» или Федеральным

законом от 18 июля 2011 года № 223-ФЗ «О закупках товаров, работ, услуг отдельными видами юридических лиц».

Документы, предусмотренные абзацами вторым, седьмым – тринадцатым части первой статьи $35^2$ настоящего Закона, а также абзацами вторым – шестым части первой настоящей статьи, представляются заявителем одновременно с подачей заявки.

Документы, предусмотренные абзацами третьим – шестым части первой статьи $35^2$ настоящего Закона, запрашиваются органом управления государственным фондом недр самостоятельно, если заявитель не представил указанные документы по собственной инициативе.»;

8) в статье $35^9$:

а) наименование после слов «без проведения» дополнить словами «конкурса или»;

б) абзац первый после слов «без проведения» дополнить словами «конкурса или».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
16 марта 2018 года
№ 11-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Җир асты байлыклары турында”**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

“Җир асты байлыклары турында” 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1999 елның 6 декабрендәге 2486 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 2 (2); 2001, № 12; 2004, № 7 (I өлеш); 2005, № 4 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 9 – 10; 2012, № 1, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 4, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 статьяга түбәндәге эчтәлекле дүртенче өлеш өстәргә:

“Гомумтаралган файдалы казылмалары булган һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренең җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы тарафыннан расланган исемлегенә кертелгән һәм әлеге Законның 16 статьясындагы унҗиденче абзацы нигезендә файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә җир асты байлыкларыннан файдаланучылар гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту эшләрен башкаруга “Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында” 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон яисә “Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында” 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә граждан-хокук шартнамәләре төзелгән юридик затлар булырга мөмкин.”;

2) 15 статьяда:

а) икенче өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту эшләре башкару чорына – гомумтаралган файдалы казылмалары булган һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренең җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы тарафыннан расланган исемлегенә кертелгән һәм әлеге Законның 16 статьясындагы унҗиденче абзацы нигезендә файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен.”;

б) бишенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану чоры, әлеге җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан лицензия шартлары бозылмау шарты белән, файдалы казылмалар ятмасын эзләүне һәм бәяләүне яисә эшкәртүне тәмамлау йә ликвидация чараларын башкару кирәк булган очракта, җир асты байлыкларыннан файдаланучы инициативасы белән озайтыла.”;

3) 16 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту эшләрен башкаруга “Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында” 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон яисә “Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында” 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән граждан-хокук шартнамәләренә таянып гамәлгә ашырыла торган шушы эшләрне башкару максатларында кирәкле булган гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен гомумтаралган файдалы казылмалары булган һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренең җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы тарафыннан расланган исемлегенә кертелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын конкурс яисә аукцион үткәрмичә бирү турында.”;

4) 21 статьяның беренче өлешендә “федераль законда” сүзләрен “законнарда” сүзенә алмаштырырга;

5) $35^1$ статьяда:

а) беренче өлештә “алтынчы” сүзен “җиденче” сүзенә алмаштырырга;

б) икенче өлештә:

беренче абзацта “хокукы” сүзеннән соң “конкурс яисә” сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту эшләрен башкаруга “Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында” 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон яисә “Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу

турында" 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән граждан-хокук шартнамәләренә таянып гамәлгә ашырыла торган шушы эшләрне башкару максатларында кирәкле булган гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару.";

6) $35^{3}$ статьяда:

а) исемендә "хокукын" сүзеннән соң "конкурс яисә" сүзләрен өстәргә;

б) икенче өлештә "$35^{8}$" саннарын "$35^{8.1}$"саннарына алмаштырырга;

7) түбәндәге эчтәлекле $35^{8.1}$ статья өстәргә:

**"$35^{8.1}$ статья. Гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту эшләрен башкару максатларында кирәкле булган гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирү өчен кирәкле документлар**

Гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту эшләрен башкаруга "Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон яисә "Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында" 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән граждан-хокук шартнамәләренә таянып гамәлгә ашырыла торган шушы эшләрне башкару максатларында кирәкле булган гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалауга һәм чыгаруга җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирү өчен әлеге Законның $35^{2}$ статьясындагы беренче өлешендә каралган документлар, шулай ук түбәндәгеләр дә кирәк:

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия алу өчен дәүләт пошлинасын түләү турындагы документ;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең топографик планы күчермәсе (өч нөсхәдә);

гариза бирелгән вакытка файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең торышын чагылдыра торган һәм эшләр башлауның планлаштырыла торган сроклары һәм җир асты байлыкларын, әйләнә-тирә мохитне саклау буенча тәкъдим ителә торган чаралар турында белешмәләр булган аңлатма;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә гомумтаралган файдалы казылмалар запасларын раслау беркетмәсенең күчермәсе;

гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту эшләрен башкаруга "Дәүләт

ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында” 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон яисә “Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында” 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән шартнамәнең күчермәсе.

Әлеге Законның $35^{2}$ статьясындагы беренче өлешенең икенче, җиденче – унөченче абзацларында, шулай ук әлеге статьяның беренче өлешендәге икенче – алтынчы абзацларында каралган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза белән бер үк вакытта тапшырыла.

Әлеге Законның $35^{2}$ статьясының беренче өлешендәге өченче – алтынчы абзацларында каралган документларны, әгәр мөрәҗәгать итүче аларны үз инициативасы белән тапшырмаган булса, җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы үзе соратып ала.”;

8) $35^{9}$ статьяда:

а) исемендә “хокукын” сүзеннән соң “конкурс яисә” сүзләрен өстәргә;

б) беренче абзацта “хокукын” сүзеннән соң “конкурс яисә” сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 16 март
№ 11-ТРЗ